ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2022 Олы Кайбыч ав. № 566

«Опека һәм попечительлек өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 08 августындагы 361 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына инвалидлык турында белешмәләр бирү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 10 февралендәге 114 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека һәм попечительлек өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 08 августындагы 361 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 апрелендәге 259 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 нче кушымтаның 3.3.3 пунктындагы «к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) балигъ булган тәрбияләнүченең инвалидлыгы турында белешмә (билгеләнгән үрнәктә), аның индивидуаль реабилитация программасы яки абилитацияләү яки балигъ булган тәрбияләнүчегә инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләр, шулай ук аны реабилитацияләү яки абилитацияләү буенча тәкъдимнәре булган белешмәләр. Мондый белешмәләрне опека һәм попечительлек органы ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан соратып ала. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара электрон багланышларның региональ системаларын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә. Тәрбияләнүче (опекун, попечитель) үз инициативасы белән балигъ булган тәрбияләнүченең инвалидлыгы

турында кирәкле белешмәләр (билгеләнгән үрнәктә), аны реабилитацияләүнең яисә абилитациянең медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән индивидуаль программасын тәкъдим итәргә хокуклы.;».

2 Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Э.Х.Заһидуллина